**Республика Татарстан**
**ЛЯКИНСКОЕ**
**СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛӘКЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел 07 нче ноябрь № 6

**Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә 2024 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ләке авылында халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгы

КАРАР чыгарды:

1. 2023 елның 17 ноябрендә 14.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы, Ләке авылы, Тау башы ур., 12 а йорт адресы буенча урнашкан Ләке мәдәният йорты бинасында 2024 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, срокли хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт үтәүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1 Ләке торак пунктында зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) Ләке торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту һәм җәйге вакытта территорияне һәм юл буе полосаларын чабу (ягулык-

майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Ләке  торак пунктында урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм лампалар урнаштыру, килешү буенча эшләргә һәм хезмәтләргә түләү);

4) Ләке  торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (гидрант сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләргә һәм хезмәтләргә түләү);

5) Ләке  торак пунктында  су коеларын ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләргә һәм хезмәтләргә түләү);

"ӘЙЕ "                " КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы                                        Антонов Ю.Г.